Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы
карары

№ 61/2 2025 елның 26 мае

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 24 сентябрендәге 70/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 24 июлендәге 370-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының "Татар Ялтаны авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында "Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы "Татар Ялтаны авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибен раслау турында" 2019 елның 24 сентябрендәге 70/1 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 пунктының 1, 1_1, 5, 9 һәм 10 пунктчаларында каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлардан тыш, әлеге карарлар кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтта ачык файдалану мөмкинлегендә урнаштырылырга тиеш.»;

15.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктча өстәргә:
«4.1) муниципаль мөлкәтне минималь рөхсәт ителгән бәядән сатканда, мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән электрон мәйданчык операторы счетына задатка кергәннән соң гына, дәгъвачы тарафыннан муниципаль мөлкәтнең бәясе турында тәкъдим бирү мөмкинлеге;».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтына www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татар Ялтаны авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарифуллин